| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| 10.12.2025 | г. Казань | № 510-118/кс-2025 |

Саба муниципаль районының «Саба районының Шәмәрдән ТКХ КҖП» акционерлык җәмгыяте өчен 2026 елга су агызуга тарифлар билгеләү һәм җитештерү программасын раслау турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә эшчәнлек алып баручы оешмаларның инвестиция һәм җитештерү программалары турында» 2013 елның 29 июлендәге 641 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.06.2010 ел, № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 10.12.2025 ел, №31-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы Саба муниципаль районының «Саба районының Шәмәрдән ТКХ КҖП» акционерлык җәмгыяте (алга таба – «Саба районының Шәмәрдән ТКХ КҖП» АҖ) өчен ташландык су агызуга календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә «Саба районының Шәмәрдән ТКХ КҖП» АҖ өчен ташландык су агызу өлкәсендә җитештерү программасын расларга.

4. Ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Саба районының Шәмәрдән ТКХ КҖП» АҖ ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында

карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В. Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
10.12.2025 № 510-118/кс-2025
карарына 1 нче кушымта

Су агызуны гамәлгә ашыручы «Саба районының Шәмәрдән ТКХ КҖП» АҖ өчен
су агызуга 2026 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|
| | | 01.01.2026 башлап 30.09.2026 кадәр | 01.10.2026 башлап 31.12.2026 кадәр |
| | Саба муниципаль районы | | |
| 1 | «Саба районының Шәмәрдән ТКХ КҖП» АҖ* | | |
| 1.1 | Кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)** | 85,82 | 106,00 |

* Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.
** Россия Федерациясе Салым кодексының 164 статьясындагы 8 пунктының 1 пунктчасында билгеләнгән салым ставкасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
10.12.2025 № 510-118/кс-2025
карарына 2 нче кушымта

<table>
<tr><td colspan="6">Оешманың җитештерү программасы</td></tr>
<tr><td colspan="6">1 нче бүлек. Җитештерү программасы паспорты</td></tr>
<tr><td colspan="2">Җайга салынулы оешма</td><td colspan="4">«Саба районы Шәмәрдән ТКХ КҖП» АҖ</td></tr>
<tr><td colspan="2">Урнашу урыны</td><td colspan="4">422050, ТР, Саба районы, Шәмәрдән авылы, Азин урамы, 6</td></tr>
<tr><td colspan="2">Җайга салучы вәкаләтле орган</td><td colspan="4">Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты</td></tr>
<tr><td colspan="2">Урнашу урыны</td><td colspan="4">420015, Казан ш., Карл Маркс ур., 66 й.</td></tr>
<tr><td colspan="2">Җитештерү программасын гамәлгә ашыру чоры</td><td>башлана</td><td>01.01.2026</td><td>тәмамлана</td><td>31.12.2026</td></tr>
<tr><td colspan="6">2 нче бүлек. Су белән тәэмин итүнең һәм ташландык суларны агызуның үзәкләштерелгән системалары объектларын ремонтлау чаралары, эчә торган суның сыйфатын һәм агып төшүче суларны чистарту сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар, энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру, шул исәптән транспортировкада су югалтуларын киметү чаралары исемлеге</td></tr>
<tr><td rowspan="2">№</td><td rowspan="2" colspan="2">Атамасы</td><td rowspan="2" colspan="2">Үлчәү берәмлеге</td><td>Гамәлгә ашыруга финанс ихтыяҗлары</td></tr>
<tr><td>2026</td></tr>
<tr><td colspan="6">1ВО - Су чыгаруга тариф</td></tr>
<tr><td>1</td><td colspan="2">Агымдагы ремонт</td><td colspan="2">мең сум</td><td>238,67</td></tr>
<tr><td>2</td><td colspan="2">Капиталь ремонт</td><td colspan="2">мең сум</td><td>0,00</td></tr>
<tr><td>3</td><td colspan="2">Башка чаралар, шул исәптән агып төшүче суларны чистарту сыйфатын яхшыртуга, энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чаралар</td><td colspan="2">мең сум</td><td>0,00</td></tr>
<tr><td colspan="6">3 нче бүлек. Су бирү күләме/Кабул ителгән су</td></tr>
<tr><td colspan="6">1ВО - Су чыгаруга тариф</td></tr>
<tr><td rowspan="2">№</td><td rowspan="2" colspan="2">Җитештерү эшчәнлеге күрсәткечләре</td><td rowspan="2" colspan="2">Үлчәү берәмлеге</td><td>Күрсәткеч зурлыгы</td></tr>
<tr><td>2026</td></tr>
<tr><td>1</td><td colspan="2">Агынты суларны кабул итү, барлыгы</td><td colspan="2">мең м3</td><td>92,80</td></tr>
<tr><td>2</td><td colspan="2">предприятиенең үз ихтыяҗлары</td><td colspan="2">мең м3</td><td>0,00</td></tr>
<tr><td>3</td><td colspan="2">Хезмәтләрне җибәрү (гамәлгә ашыру), барысы да, шул исәптән:</td><td colspan="2">мең м3</td><td>92,80</td></tr>
<tr><td>3.1</td><td colspan="2">бюджет оешмаларына</td><td colspan="2">мең м3</td><td>18,58</td></tr>
<tr><td>3.2</td><td colspan="2">халыкка</td><td colspan="2">мең м3</td><td>71,32</td></tr>
<tr><td>3.3</td><td colspan="2">башка кулланучылар</td><td colspan="2">мең м3</td><td>1,89</td></tr>
</table>

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3.4 | башка канализацияләрдән кабул ителгән агынты сулар | мең м3 | 0,00 |
| 4 | Агынты суларның исәпкә алынмаган агымы | мең м3 | 0,00 |
| 5 | Транспортлана торган агынты сулар күләме | мең м3 | 0,00 |
| 5.1 | Үз чистарту корылмалары аша үткәрелгән | мең м3 | 0,00 |
| 5.2 | Башка канализацияләргә тапшырылган агынты сулар | мең м3 | 0,00 |
| 6 | Чистарту корылмалары белән җиһазландырылмаган су чыгару торбалары аша үткәрелгән агынты су күләме | мең м3 | 0,00 |
| **4 нче бүлек. Җитештерү программасын гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс ихтыяҗлары күләме** | | | |
| **№** | **Күрсәткечнең атамасы** | **Үлчәү берәмлеге** | **Күрсәткеч зурлыгы** |
| | | | **2026** |
| 1 | Җитештерү чыгымнары | мең сум | 6 857,46 |
| 1.1 | Хезмәт өчен түләү һәм төп җитештерү персоналының социаль ихтыяҗларына түләүләр чыгымнары | мең сум | 4 998,32 |
| 2 | Ремонт чыгымнары | мең сум | 238,67 |
| 3 | Административ чыгымнар | мең сум | 386,03 |
| 4 | Сату чыгымнары | мең сум | 0,00 |
| 5 | Амортизация | мең сум | 416,30 |
| 6 | Аренда һәм концессия түләүләре, лизинг түләүләре | мең сум | 10,20 |
| 7 | Салымнар һәм җыемнар | мең сум | 121,80 |
| 8 | Норматив табыш | мең сум | 0,00 |
| 8.1 | Капиталь чыгымнар | мең сум | 0,00 |
| 9 | Гарантияләүче оешманың исәпләмә эшкуарлык табышы | мең сум | 0,00 |
| 10 | Узган чорларның алынмаган керемнәре / чыгымнары | мең сум | 0,00 |
| 10.1 | Узган чорда тарифлар билгеләгәндә тарифларны җайга салу органы тарафыннан исәпкә алынмаган икътисадый нигезләнгән чыгымнар | мең сум | 0,00 |
| 10.2 | Җайга салуның узган чорларында алынмаган керемнәр | мең сум | 0,00 |
| 10.3 | Акча җитмәүне каплауга юнәлдерелгән заем акчаларына һәм үз акчаларына хезмәт күрсәтүгә бәйле чыгымнар | мең сум | 0,00 |
| 11 | Җайга салуның узган чорларының икътисадый яктан нигезләнмәгән керемнәре / чыгымнары | мең сум | 0,00 |
| 12 | Кирәкле тулай керем | мең сум | 8 030,46 |
| **5 нче бүлек. Җитештерү программасы чараларын гамәлгә ашыру графигы** | | | |
| **№** | **Чараның атамасы** | **план чоры** | |
| 1 | Төп җайланмаларны ремонтлау | 2026 | |
| **6 нчы бүлек. Су белән тәэмин итүнең һәм ташландык суларны агызуның үзәкләштерелгән системалары объектларының ышанычлылыгы, сыйфаты һәм энергетик нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең пландагы күрсәткечләре** | | | |
| **№** | **Күрсәткечнең атамасы** | **Үлчәү берәмлеге** | **Күрсәткеч зурлыгы** |

| | | | 2026 |
|---|---|---|---|
| 1ВО - Су чыгаруга тариф | | | |
| 1 | Агынты суларны чистарту сыйфаты күрсәткечләре | | |
| 1.1 | Дсвно – Үзәкләштерелгән гомуми агызу яисә көнкүреш су агызу системаларына ташлана торган агынты суларның гомуми күләмендә чистартылмый торган агынты су өлеше | % | 0,00 |
| 1.2 | Днн – Ташландык суларны ташлауның билгеләнгән нормативларына, ташландык суларны ташлау лимитларына туры килми торган агынты су пробаларының үзәкләштерелгән гомуми агызу (көнкүреш) системасы төренә карата исәпләнгән өлеше | % | 0,00 |
| 2 | Су белән тәэмин итүнең ышанычлылыгы һәм өзлексезлеге күрсәткечләре | | |
| 2.1 | Пн – Канализация челтәренең озынлыгына исәпләгәндә аварияләрнең һәм чүп-чарларның чагыштырма саны | бер./км | - |
| 3 | Энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | | |
| 3.1 | Урост – технологик процесста кулланыла торган электр энергиясенең чагыштырма чыгымы | кВт*сәг/куб.м | 0,00 |
| 3.2 | Урп - ташландык суларны транспортировкалауның технологик процессында кулланыла торган электр энергиясенең ташландык сулар күләме берәмлегенә чагыштырма чыгымы | кВт*сәг/куб.м | |

**7 нче бүлек. Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системалары объектларының ышанычлылыгы, сыйфаты һәм энергетик нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең пландагы күрсәткечләренең һәм җитештерү программасын гамәлгә ашыру чыгымнарының аның гамәлдә булу чоры дәвамында үзгәреш динамикасын чагыштыру юлы белән гамәлгә ашырыла торган җитештерү программасының нәтиҗәлелеген исәпләү**

| № | Күрсәткечнең атамасы | Үлчәү берәмлеге | Планлаштырыла торган чор күрсәткече зурлыгы |
|---|---|---|---|
| | | | 2026 |
| 1ВО - Су чыгаруга тариф | | | |
| | Үзгәреш динамикасын чагыштыру | % | Ышанычлылык, сыйфат һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең пландагы күрсәткечләре үзгәрешсез билгеләнә |

**8 нче бүлек. Җайга салуның узган чорында җитештерү программасының үтәлеше турында хисап**

Җайга салуның узган чорында җитештерү программасының үтәлеше турындагы хисап оешманың 2024 елгы финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләре турындагы хисабы составында бирелгән

**9 нчы бүлек. Абонентларга хезмәт күрсәтү сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар**

| № | Абонентларга хезмәт күрсәтү сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар каралмаган |
|---|---|

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге